УДК 398

***О.Р. Хисамов,***
***И.Г. Закирова***

# СЕБЕР ТАТАРЛАРЫ ФОЛЬКЛОРЫНДА ТОПОНИМНАРНЫҢ ЧАГЫЛЫШЫ

В статье выявлены топонимы и микротопонимы в фольклорных текстах сибирских татар, определены особенности взаимосвязи фольклора и топонимики. Анализ топонимической лексики в фольклоре сибирских татар позволит сделать выводы о национально-культурном своеобразии представлений о пространстве, которые могут быть реконструированы по топонимическим данным. Фольклорная топонимия является средством передачи топонимической версии этнокультурной информации в представлениях сибирских татар и источником изучения восточного диалекта татарского языка.

**Ключевые слова:** топонимы, микротопонимы, восточный диалект татарского языка, сибирские татары, фольклор, фольклорная топонимия, топонимические легенды, топоосновы, поэтические топонимы.

The article identifies toponyms and microtoonyms in the folklore texts of the Siberian Tatars, identifies the peculiarities of the interrelation between folklore and toponymy. The analysis of toponymic vocabulary in the folklore of the Siberian Tatars, will make it possible to draw conclusions about the national and cultural originality of ideas about space, which can be reconstructed from toponymic data. Folklore toponymy is a means of transmitting a toponymic version of ethnocultural information in the ideas of Siberian Tatars and a source for studying the eastern dialect of the Tatar language.

**Keywords:** toponyms, microtoponyms, eastern dialect of the Tatar language, Siberian Tatars, folklore, folklore toponymy, toponymic legends, toponyms, poetic toponyms.

Төрле елларда тупланган һәм язмача теркәлгән фольклор текстлары алар язып алынган төбәкләрнең топонимиясен өйрәнү өчен дә кыйммәтле чыганак булып тора. Бу Себернең төрле регионнарында яшәгән татарлардан язып алынган фольклорга да карый. Халык иҗатында сакланган топонимнар үзләре Себер татарларының башка халыклар белән сәяси һәм икътисади элемтәләрен, рухи мирасын өйрәнү өчен материал булып, төрки халыкларның дөнья картинасын реконструкцияләү мөмкинлеге бирә.

Татар теленең көнчыгыш диалектында сөйләшкән Себер татарлары, нигездә, Омск, Томск, Төмән, Новосибирск өлкәләрендә яшиләр. Себер татарларының тел үзенчәлекләре, бай милли традицияләре, халык иҗаты галимнәр тарафыннан күпсанлы экспедицияләр вакытында язып алынып, хәзерге вакытта яхшы өйрәнелгән. Татар тел белемендә әлегә кадәр чагыштырмача аз өйрәнелгән өлкәләрнең берсе – Себер татарларының топонимиясе һәм микротопонимиясе.

Топонимия – тел белеменең халыкның дөньяны танып-белүе, дөнья картинасы, пространствоны үзләштерү турында мәгълүмат саклаган өлеше. Топонимнар фольклор әсәрләре текстларына кереп, алар язмача теркәлгән очракта, киләчәк буыннарга барып җитә. Мәгълүм булганча, Себердә дә бик күп татар авыллары юкка чыккан, бу процесс хәзер дә дәвам итә. Авыллар белән аларның топонимнары һәм бигрәк тә микротопонимнары да югала бара. Глобальләшү чорының фаҗигасы – буыннар арасындагы элемтә өзелү дә микротопонимнарның яшь буынга тапшырылмавына, аларның онытылуына китерә. Тагын бер күренешне искә алмыйча булмый: халык, ул регионнардагы татар мәктәпләре ябылу белән, рус теленә күчә бара, бу да топонимнарның югалуына, рухи дөньяның бер чылбыры юкка чыгуга китерә.

Г.П. Смолицкая, топонимнарны өйрәнү өчен язма чыганакларның әһәмиятен билгеләп, «лингвотарихи характердагы иң зур мәгълүматны иң борынгы чыганактан (язма истәлектән) алынган топоним бирәчәк. Чыганак никадәр борынгырак булса, топоним (яки гидроним) беренчел формага шулкадәр якынрак язылган була», дип яза [Смолицкая, 1972, с. 11].

Себер татарлары фольклорының беренче үрнәкләре, В.В. Радлов тарафыннан 1859–1871 елларда язмача теркәлеп, 1872 елда галимнең «Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи» дигән хезмәтенең IV томы булып басылып чыга [Радлов, 1872, с. 11]. Хәзерге вакытта бу хезмәт фольклорчылар өчен дә, тел белгечләре өчен дә кыйммәтле чыганак булып тора. Себер татарларының тарихи риваятьләрен Н.Ф. Катанов та җыйган һәм бастырып чыгарган.

Татарлардан Себер татарларының фольклорын беренчеләрдән булып Хафиз Рәхмәтуллин җыя башлаган. Ул үзе дә – Себер татары, 1894 елда Омск өлкәсенең Усть-Ишим районы Тау авылында туган. Хафиз Рәхмәтуллин 1928 елдан 1936 елга кадәр Новосибирск өлкәсендә төрле вазифалар башкара. 1932–1936 елларда «Азат Себер» газетасында редактор урынбасары һәм баш редактор булып эшли, киң эрудицияле, күпкырлы талантлы шәхес булып, Себер татарларының рухи байлыгын туплау һәм киләчәк өчен саклап калу өчен зур хезмәт куя. Себер татарларының күпсанлы җырларын, әкиятләрен, дастаннарын әлеге шәхес кәгазьгә теркәгән, шул сәбәпле алар сакланып калган. Хафиз Рәхмәтуллин Новосибирск өлкәсендә эшләгән дәверендә шактый гына топонимнар һәм микротопонимнарны саклаган Әйтүкә җырын да язып алган.

1939 елдан башлап Себер татарларының фольклорын һәм тел үзенчәлекләрен Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре планлы рәвештә өйрәнә башлый. Күпсанлы фәнни экспедицияләр вакытында язып алынган материал төрле җыентыкларда дөнья күрә. Себер татарларының фольклорын җыю һәм өйрәнү белән Ф.В. Әхмәтова, Ф.И. Урманчеев, Х. Ярми шөгыльләнәләр. ТӘһСИнең Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә институтның беренче көн-

нәреннән оештырылган экспедицияләр вакытында тупланган фольклор материаллары саклана. Биредә Себер татарлары яшәгән барлык төбәкләрдә язып алынган бай фольклор мирасы тупланган.

Себер татарларының фольклор үрнәкләре диалектолог Л.В. Дмитриева тарафыннан аерым китап итеп чыгарылган. Күпсанлы экспедицияләр вакытында халык авыз иҗаты буенча бай материал Казан дәүләт университеты һәм Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре Ф.Й. Юсупов, Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова тарафыннан язып алынган һәм бастырылган.

Себер татарларының рухи мирасын өйрәнүгә багышланган экспедицияләр соңгы елларда тагын да җанланып китте. Диалектолог галимнәр катнашындагы әлеге экспедицияләрдә өйрәнү өчен бай материал, шул исәптән топонимик характердагы риваятьләр һәм легендалар да язып алынды. Себер татарлары фольклоры буенча гасыр ярым вакыт аралыгында язып алынган материаллар булу Себер татарлары топонимиясендәге үзгәрешләрне күзәтергә мөмкинлек бирә. Соңгы экспедицияләр барышында теркәлгән топонимик риваятьләр О.Р. Хисамов тарафыннан тикшерелә [Хисамов, 1915, б. 14 – 37; 2016, б. 11 – 52; 2017, б. 11 – 64].

Себер татарлары фольклорында халыкның яшәү урыны, географиясе, тарихы, тормыш рәвеше, ышанулары, мифологиясе белән бәйле топонимнар системасы формалашкан. Фольклор әсәрләрендә бер жанрдан икенчесенә күчә торган, исемнәре булмаган топонигезләр – тау, елга, диңгез һ.б. да, поэтик топонимнар да очрый. Кайбер топонимнарны аерым бер жанрга караган әсәрләрдә генә дә күрергә мөмкин. Шул ук вакытта Себер татарлары фольклоры топонимиясе халык яшәгән территорияләрнең географиясен яхшы күзалларга мөмкинлек бирә. Һәр халык үзенең фольклорында үзенә яхшы таныш булган пространствоны тасвирлый. Себер татарларының фольклорында ландшафтның түбәндәге элементлары теркәлгән: урман-тайга, сазлыклар, күлләр, зур һәм кечкенә елгалар, калкулыклар-таулар, болынкырлар. Халыкның хуҗалык эшчәнлеге сулыклар белән тыгыз бәйләнгән, урман да мөһим роль уйный. Шуңа күрә текстларда шушы элементлар ешрак очрый.

Фольклор пространствосы *диңгез (диңгез кырые, диңгез төбе, дәрья, дәрьяның ягасы), шәһәр (тора, кала, үз шәһәре, шәһәр эче, шәһәр уртасы) тау (тау, тау башы, тау итәге, тау тишеге, тау култыгы), авыл, урман (урман, урман итәге, еш, төс), утрау (атау, утрау), елга (әйри, елга, дәрья), күл, кыр (кыр, уй, ялан, үзән, сахра)* кебек реаль географик объектлардан формалаша. Себер татарларының фольклорында *уй/ой, шар/шор, еш, әйре/әйри, уба, түс/төс* диалекталь географик терминнары кулланыла, алар Себер татарларының Алтай халыклары, монголлар, төньяк халыклары белән иң борынгы бәйләнешен күрсәтә.

Шунысы кызык: соңгы экспедицияләр вакытында Себер татарларының җырларында, легенда-риваятьләрендә еш очраган *шар/шор* географик термины В.В. Радлов тарафыннан теркәлмәгән.

Фольклор топонимиясен күзәтү өчен материал буларак, Себер татарларының әкиятләренә, батырлык һәм тарихи дастаннарга мөрәҗәгать итәбез. Төрле жанрда очраган топонимнарның семантикасы төрлечә ачыла. Бу топонимик объектның чынбарлыктан алынуына яки уйлап чыгарылган булуына, пространствоны кабул итү үзенчәлегенә, һәр халыкның мифологиясенә һәм традицияләренә бәйле. Аерым жанрларның халыкның пространствоны мифопоэтик кабул итүләре чагылган традицион төрләре дә була. Бу жанрларның һәрберсенең үзенә генә хас тотрыклы топонимиясе бар.

Себер татарларының эпик фольклорын тәшкил иткән дастаннар һәм әкиятләрнең топонимиясе конкрет атамаларга бай түгел. Халык әкиятләре топонимиясе уйлап чыгарылган, ягъни әкият сюжеты әкияти пространствода үсә. А.В. Терещенко, фольклор әсәрләрендәге топонимнарның кулланылыш үзенчәлекләрен тикшергәннән соң, «географик атаманың (топонимның) семантикасы – лингво- һәм этномәдәни әкияти пространство турында мәгълүматның төп чыганагы» дип күрсәтә [Терещенко, 2014, с. 81]. Себер татарларының әкияти пространствосы халыкның үз һәм ят дөньялар турындагы мифологик күзаллауларына туры килә. Әкияти пространство үз җирен дә *(«безнең җир»)* һәм теге дөньяны да *(«теге җир, чит җир, башка җир, икенче җир»)* белдерә ала. Чит, теге дөнья утлы тау яки диңгез артында, җир астында, кара урманда урнаша ала. Башка дөньяга эләгү өчен, герой кире кайту юлы булмаган ике дөнья чиген үтәргә тиеш. Икенче дөньяны атау өчен кулланылган әкияти топонимнар күп түгел, алар татар халык әкиятләре өчен традицион булып, тексттан текстка күчә баралар: *кайтмаслык җир, кайтмас җир, кеше аягы басмаган җир, үзем белмәгән җир*. *Атҗитмәс шәһәр, Узмас патшаның шәһәре* кебек топонимнар да икенче дөньяга ишарәле. *«Кайтмас җир»* эпик топонимы төрки эпос буенча мәгълүм *«барса – килмәс»* топонимының синонимы булып тора. Әкиятләрдә *«ат килсә, тоягы көя, кош килсә, канаты көя торган җир»* («Ак бүре») кебек топонимнар да очрый. Татар тылсымлы әкиятләре һәм мифологиясендә *Каф тавы* традицион оронимына юлыктык. Аның төрки халыкларда фонетик вариантлары шактый, *Кәп тавы* (казакъ), *Кәйкабы* (кыргыз) һ.б. Әкият топонимнары борынгылар теге дөньяны урнаштырган ерак һәм билгесез территорияләрне белдерәләр. Ят җир (чит җир) пространствоны үз һәм ят дөньяга бүлү оппозициясе нигезендә ирреаль дөньяга карый.

Татар әкиятләрендә билгесез урынны күрсәтер өчен *«фәлән»* сүзе еш кулланыла. Ул астионим буларак та, хороним буларак та кулланыла. Фәлән шәһәр яки фәлән җир билгесез урынны күрсәтә. Шул ук вакытта аның төгәл билгеле булуы мөһим булмаганда да, шартлы булганда да бу сүз ярдәмгә килә. Себер татарларының әкияти пространствосында реаль топонимнар очрамый.

Себер татарлары экиятләрендә геройның биографиясе шәһәрләр (*шәһир, тора, кала*) белән бәйле. Шәһәрләр аерым бер объектка бәйле түгел, кагыйдә буларак, ирекле локумнар кулланыла. Аларның атамасы юк. Дастан герое үз шәһәреннән икенче шәһәргә чыгып китә. Туган шәһәре – аның үз җире, дөньяның үзәге. Себер татарларының экиятләрендә һәм эпосында авыллар (*айыл, аулцыгац, әүл, йорт*) сирәк телгә алына.

Мифологик ышанулар буенча, герой үз җиреннән чыгып китүгә, ике дөнья арасындагы чикне үтеп, ятлар дөньясына, икенче дөньяга барып чыга. Ике дөнья арасындагы чик ролен, нигездә, елга үти. Герой юлда *тәрья/дәрья* янына барып чыга. Эпик геройның һәрвакыт су буена баруы, бер яктан, төрки мифология белән бәйле булса, икенче яктан, Себер татарларының тормыш-көнкүрешен дә чагылдыра. Балык тоту – Себер татарларының төп шөгыльләреннән. Фольклор әсәрләрендә сулыклардан *әйри/әйре, көл/күл, елга, елга әйри* географик ландшафт терминнары да очрый. Бу географик терминнар фольклорда топоним ролен дә үти.

Мифологик ышанулар буенча елга яки сулык – дөньялар арасында чик, чит дөньяга юл, үлеләр дөньясы, мифологик персонажларның яшәү урыны. 2014 ел Омск өлкәсендә узган экспедиция вакытында язып алынган Иртыш елгасында боз озату йоласы бу ышануларның хәзергә кадәр яшәвен күрсәтә. Иртыш – Төньяк боз океанына ага торган елга, Төньяк боз океанын Омск өлкәсендә яши торган татарлар *Мәңгелек* дип аңлаталар һәм боз озатканда *Мәңкә бабайга* / *Мәңгәли бабайга* – төньяк рухына сәлам әйтәләр. Информантлардан язып алынган материал буенча, Иртыш елгасы ике дөньяны бәйләп торган чик булып аңлашыла. Томск өлкәсендә язып алынган материалларда да бу ышануның эзләре саклана [Закирова, 2015, б. 258].

Эпик герой юлында таулар очрый. Тылсымлы экиятләрдә *Янар тау, ком тавы, ут тавы, таш тавы, мәрмәр тавы «фәлән җиргә барып җиткәч, ут тавы булыр, – ди. – Янар тау, әгәр шуңа менеп җитә алсагыз, анда булыр өч йорт»* («Ут гармуны») *«Каф тавының башына илтеп куярмын, аннан ары барырга миңа рөхсәт юк»* («Ак бүре») искә алына [Татар, 1977, т. 1, б. 203].

Тылсымлы экиятләрнең топонимнары халыкның мифологик күзаллаулары белән бәйләнгән.

Топонимнарны саклау ягыннан дастаннар аерым әһәмияткә ия. Татар дастаннарын борынгы архаик, ягъни алыплар турындагы, героик, романик һәм тарихи төрләргә бүлү кабул ителгән.

Алыплар турындагы дастаннар эчтәлекләре белән тылсымлы экиятләргә якын булып, бу жанр төренә караган әсәрләрнең топонимиконы да экиятләрнеке белән аваздаш. Эпик топонимия халыкның мифологик карашларына нигезләнгән. Әмма шул ук вакытта дастан текстларында архаик һәм диалекталь топонимнар күбрәк саклана. Бу дастаннарның язып алу вакыты белән дә, эпос текстының тотрыклы тезмә өлешләре булу белән дә бәйле. Бу яктан В.В. Радлов

тарафыннан тупланган дастаннар аерым кыйммәткә ия. Топонимнар тезмә өлешләрдә яхшырак саклана. Себер татарларының дастаннарында түбәндәге географик объект терминнары очрый.

Бараба татарларына хас кайбер топонимнарга тукталып үтик. *Тәрйа* – фарсы теленнән кергән *дәрья* сүзе. Татар телендә *дәрья* сүзе зур су, зур елга яки диңгез мәгънәсендә кулланылган, хәзерге вакытта күбрәк шигърияттә очрый, архаизмга әйләнеп бара дияргә мөмкин. Бараба сөйләшенә караган фольклор әсәрләрендә *тәрья* топонигезе белән ясалган *тәрйа ягазы/ягасы, тәрйа ар ягы, тәрйаның ортазы* дигән топонимнар да очрый. Мәгънә ягыннан зур су, зур елга яки диңгезне аңлата; *Кыр* – урмансыз тигезлек, ачык мәйдан яки иген игү мәйданы. Бараба сөйләшенә караган фольклор әсәрләрендә тигез ачык мәйданны белдерә. *Ой* – уйсу җир, уйсулык; *орман* (урман) – тайга, *карорман*; *тау – тау, тау колтугу, тау башы* дигән топонигезләр дә очрый; *цө* – чүл, *сахра цөл варианты да бар.* Чүлләр Себер татарлары яшәгән ландшафт өчен характерлы түгел. Фольклорга әдәбият аша кергән; *елга, елга әйри, әйри/әйре, елга кашы – елга* һәм *әйри/әйре* синоним сүзләр. Алар фольклорда аерым-аерым да, янәшә дә кулланылалар; *ялан* – ачык кыр, болын; *күл, оймат көл* – күл; *үзән, үзәннән кырга чыкмак җир* – озынга сузылган тигез түбәнлек.

В.В. Радлов тарафыннан «Тара, тоболык, төмән» дип бирелгән территорияләрдә язып алынган материалларда түбәндәге ландшафт терминнары очрый:

*Сакра* – тигезлек, кыр. *Сәхрә* сүзе гарәп теленнән кергән, ике мәгънәсе бар: 1) чүл; 2) матур күренешле табигать, болын; *дәрья ягасы, дәрья кашы* – елга яры; *отрау, тәңис утрау* – утрау; *түбә* – биек булмаган тау; *су* – елга яки күл; *тиңис* – диңгез; *сас* – саз; *агац* – урман, тайга мәгънәсендә.

Батырлар турындагы дастаннарда, әкиятләрдән аермалы буларак, топонимнар да очрый. Мәсәлән, «Ак Күбек» дастанының бараба татарлары вариантында *Күрләк дигән улу су, Шарлак дигән үзән, Манар тау топонимнары* сакланган [Радлов, 1972, с. 53]. *Манар тау* топонимы дастанның тара татарлары вариантында да кабатлана [Радлов, 1972, с. 148]. Бу топонимнарның беренче икесенең нигезендә төрки сүзләр ята. *Күрләк (Курляк)* – Кемерово өлкәсендәге елга. Безнең фикеребезчә, бу топоним – бараба сөйләшендәге *гөрләү (агу)* сүзеннән. Татар телендә язгы суларны да гөрләвек дип атыйлар. Бу сүз суның гөрләп, тавышланып агуыннан чыгып ясалган. *Шарлак* топонимының нигезендә дә шул ук мәгънә ята. *Шарлавык* сүзе дә тавышланып аккан суны белдерә. *Шарлак* сүзе төрки халыкларда үзара якын берничә мәгънәдә кулланыла. Нигездә, ул зур булмаган сулыкны белдерә. *Манар* топонимының татар телендә мәгънәсе сакланмаган. Казакъ теленнән *Манар тау Ак тау* дип дип тәрҗемә ителә.

Алыплар турындагы һәм героик дастаннар тарихилыкка дәгъва итмәү сәбәпле, бу топонимнар реаль географик объектларны атаудан бигрәк, шартлы дөньяны белдерәләр, дип фараз итәбез.

Дастаннарның эчтәлеге, тасвирланган вакыйгалар аерым локуска бәйле түгел.

Батырлар турындагы дастаннарның традицион эпик топонимнары да формалашкин. Алар батырның ике дөнья арасындагы сәяхәтен, арадагы чикне сурәтлиләр һәм атыйлар:

*Атлар айланбас ала тау*
*Цыцканнар үтмәс карорман* [Радлов, 1972, с. 12];

*Куцкацак уцпас куба цөл, сауцкан уцпас сары цөл* [Радлов, 1972, с. 12, 13, 22, 59, 72]; *Канатлу учмас йәр иди, аяклу йүрмәс йәр иди* [Радлов, 1972, с. 74]; *Йәрниң пүткән йәриндә* [Радлов, 1972, с. 79].

Батырлар турындагы һәм героик дастаннардан аермалы буларак, тарихи дастаннарда геройның эш-гамәлләре реаль географик объектлар белән бәйле. Аларда чынбарлыктагы географик объектлар, сәүдә, халыкларның күчү юллары, сугышлар һәм бәрелешләрнең урыны төгәл күрсәтелә, тарихи документлар аша билгеле илләр, дәүләтләр, шәһәрләр, елга-күлләр искә алына.

Тарихи һәм географик яктан мәгълүм топонимнарны искә алу фольклор әсәренең төгәллеген һәм документальлеккә дәгъвасын арттыра.

В.В. Радлов Себер татарларыннан берничә вариантын язып алган «Идегәй» («Идегә Пи», «Токтамыш хан», «Токтамыш кан»), «Аксак Тимир» дастаннарында реаль пространство бәйланышлары һәм геройларның төгәл маршруты күрсәтелә: *Әдил билә Йайык су, Идел йурт, ак Идел, Сат Тимир Канның йурты, Сат Тимир Кан шәһәре, Сыңгыс шәһәре, Мәгә (Мәккә).*

Соңгы топонимнардан аерым дәүләтләрне яки шәһәрләрне хөкемдар исеме белән атау традициясе күзәтелә. *Сат Тимер Канның йурты* дип, Аксак Тимер төзегән дәүләт тә, ул яшәгән шәһәр дә атала ала. *Сан Тимир Кан шәһәре* дип Сәмәрканд атала. *Сыңгыс шәһәре* дигәндә дә 1220 елның язында Чыңгыз хан яулап алган Сәмәрканд күз алдында тотылырга мөмкин.

Топонимнарның антропонимнар аша барлыкка килү традициясе «Казах халкының әдәтләри» дигән дастанда бәян ителә:

*Күп йындан суң Бутай тигән бир ир тоуды,*
*Тили аның шикәр шигилли татлы булды,*
*Ул әүлгә шу Бутай ханы булды,*
*Казах халыны Бутай әүли исм койды инди* [Радлов, 1872, с. 171].

Фольклор текстларында сакланган топонимнарны күзәтеп, без түбәндәге нәтиҗәләргә киләбез. Фольклор топонимнары һәм халык географик терминнары Көнбатыш Себердә яшәүче Себер татарларының һәм төрки халыкларның топонимик системасын алга таба өйрәнү өчен бай һәм уникаль материал булып тора. Фольклор текстларында реаль һәм уйлап чыгарылган топонимнар кулланыла. Топонимнар халык авыз иҗаты әсәрләрен төгәлрәк, географик яктан

мәгълүматлырак итә. Әкияти яки эпик топонимнар Себер татарларының параллель дөнья турындагы күзаллауларын чагылдыра. Фольклор топонимнарын анализлау халыкның мәдәни-тарихи үсешен реконструкцияләргә, тарихи мәгълүматларны тулыландырырга, халыкның тарихи вакыйгаларга мөнәсәбәтен ачыкларга мөмкинлек бирә. Фольклор топонимнарны үзендә консервацияли һәм, шул рәвешле, атамаларны юкка чыгудан саклый.

**Әдәбият**

*Закирова И.Г.* Мәңгелеккә аккан сулар бар // Милли-мәдәни мирасыбыз: Омск өлкәсе татарлары. Казан, 2015. Б. 240–267.

*Радлов В.В.* Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи: в 12-ти т. СПб.: Тип. Акад. наук, 1872. Т. IV. Наречия барабинцев, тарских, тобольских и тюменских татар. 411 с.

*Смолицкая Г. П.* Писцовые книги как источник топонимии // Вопросы топонимики СССР: материалы топонимической комиссии 1970/71 и 1971/72 гг.: сборник / отв. ред. Е. М. Поспелов. М., 1972. С. 11–13.

Татар халык иҗаты: Әкиятләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. Т. 1. 407 б.; 1978. Т. 2. 448 б.

*Терещенко А.В.* Особенности функционирования топонимов в селькупских фольклорных и бытовых рассказах // Вестник Томского государственного педагогического университета. 2014. № 10. С. 81–85.

*Хисамов О.Р*. Барабинские татары: история и топонимика // Милли-мәдәни мирасыбыз: Новосибирск өлкәсе татарлары. Казань, 2016. С. 11–64.

*Хисамов О.Р*. История тевризских татар в топонимах // Милли-мәдәни мирасыбыз: Омск өлкәсе татарлары. Казань, 2015. С. 14–37.

*Хисамов О.Р.* Тюрко-татарская топонимия Томской области // Милли-мәдәни мирасыбыз: Томск өлкәсе татарлары. Казань, 2016. С. 11–52.

***Хисамов Олег Ришат улы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директорының фән эшләре буенча урынбасары*

***Закирова Илсөяр Гамил кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*